# Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru


*Татарстанда язылу индексы – П2355.*

№ 47 (1514) 29 ноябрь 2024 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:


madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



2-4


**Кадере көн-нән-көн китә барган Ана телебезне саклап калу өчен галимнәр һәм әдипләр ару-талу белми көрәшә.**


11

**Фашистлар кулына әсирлеккә төшкән 120 генерал арасыннан Дмитрий Карбышев һәм Петр Новиков кебек керәшен татарлары, дошманга сатылмыйча, Ватанга тугры калып һәлак була.**


16-17

**Татар милләтенең иң асыл нәселләреннән булган Терегуловлар туган халкын гына түгел, безгә якын азәрбайҗаннарны да баета.**



# Бөек әдип, бөек галим рухын Бар халкыбыз бүген яд итә!..

## БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Болгар ислам академиясе ректоры Фәрхәт Хөснетдиновка «Дуслык» ордены тапшырды.
- Минзәлә үзәк китапханәсендә танылган шагыйрә, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Мәдәният министрлыгының һәм Татарстан Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты Салисә Гәрәеваның «Бер кайтырмын» дип аталган яңа китабын тәкъдим итү кичәсе үтте.
- Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетының концертлар залында 2024 елның XXVI, XXVII, XXVIII һәм XXIX «Әдәби марафон» проекты финалистларын, «Заманча шигъри әлифба» рәсемнәр бәйгесе җиңүчеләрен һәм аларның остазларын бүләкләү тантанасы булып узды.
- Казан федераль университетының актлар залында «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсенең 80 еллык юбилее билгеләп үтелде.
- Мәскәү өлкәсендәге Химки шәһәр округының Мөселман үзәгендә РФ мөселманнары Диния нәзарәте Мәдәният департаменты белән округның мөселман җәмәгатьчелеге оештырган «Ислам миниатюраларда» күргәзмәсе ачылды.
- Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор, Сарман районының мактаулы гражданы Вәсим Әхмәтшин һәм аның хатыны – ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Асия ханым И.Шакиров исемендәге балалар сәнгать мәктәбенә тугыз уен коралы бүләк итте.
- Казан шәһәренең В.И. Ленин исемендәге мәдәни-ял комплексында Барда районы җирлегенең 100 еллыгына багышланган «Саумы, Казан – рухи башкала!» дип аталган зур концерт булып узды.

podpiska.pochta.ru

# Парлы мендәрләр онытылмый

*«Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурс-фестивале кысаларында Казан тамашачылары алдында чираттагы имтихан бирүчеләр Мөслим районы делегациясе булды. Әлеге конкурс республикабызда икенче ел гына уздырылса да, башкалабыз тамашачылары аны яратып өлгерде инде.*




Сер түгел, элегрәк район һәвәскәрләре иҗади хисап концерт программасы белән килгәндә, залны тутырып булырмы икән, дигән борчылу булса, хәзер алданрак килеп урын алып куймасаң, утырырга урын калмавы да ихтимал. Әнә Норлат, Азнакай, Чүпрәле, Аксубай районнары талантлары тамашасын байтак кеше яратып, баскан килеш карады. Хәер, Мөслим районы чыгышын караргa да йөзләгән кеше җыеласына шик юк иде. Шулай булды да. Беренче катта да, икенче катта да халык шыгрым тулы булды, утырырга урындыклар җитмәде. Миңа калса, концерт түләүле булса да, тамашачы аз булмаячак. Беренчедән, әлеге тамашага башкалада яшәүче мөслимнәр аралашырга, якташларын күрергә дип килә. Икенчедән, күргәзмә-ярминкәдә туган якта үскән җиләк-җимештән, каз-үрдәктән әзерләнгән ризыклар, бавырсак, кош теле кебек тәм-том сатып алып кинәнә. Өченчедән, концерт-тамашада җитез-оста биючеләрен, моңлы җырчыларын күреп-тыңлап ләззәтләнә.

– Авыллардагы фольклор коллективлары мондый ярышларга әзер булса да, хәзер яңа костюмнар тегелә, әбиләр сандыгында яткан чигүле күлмәкләр табыла башлады. Гади генә чыгыш түгел инде бу. Гаилә тарихлары, нәселләр, халык хуҗалыгының төрле тармагында үзләрен күрсәткән матур гаиләләр тәкъдим ителә. Билгеле, ике-өч атна гына репетиция ясаган коллективлар белән ике-өч ай әзерләнгән коллективлар аерыла, кайберләрендә кытыршылыклар сизелә, – дип сөйләде тамаша алдыннан жюри әгъзасы, Татарстан Милли музее методисты Лилия Хисаметдинова. – Күргәзмә өлеше белән концерт өлеше бер-берсен тулыландырырга тиеш. Күргәзмәдә күргәннәр тамашада дәвам итсен, бер җепкә тезелеп барсын. Шул күркәм гаиләләр сәхнәдә дә чыгыш ясасын. Быел гаилә елы булгач, гаилә темасы үзәктә торсын.

Миңа калса, мөслимнәрнең чыгышы жюри таләпләренә тулысынча туры килде. Ленин исемендәге мәдәният йортының фойесы чигүле сөлгеләр, мендәрләр, башка чигү эшләре, сыннар, ишле гаиләләрнең шәҗәрәләре, шәмаилләр белән бизәлгән. Районның оста гармунчылары халкыбызның яраткан моңнарын сыздыра. Җирле аш-су осталары пешергән ризыклар чакырып тора. Мөслим гимназиясе директоры Азат Мирзаянов, нәсел тамырларын өйрәнеп, уникенче буынга кадәр төшеп җитә алган икән. Мөслимдә туып үскән каләм әһелләренең иҗат җимешләре кусалган өстәл янында да кызыксынып караучылар күп. Тойгелде авылында яшәүче сабакташым Марсель Гыйльфановның «Офык артында офык», «Шук кояш» шигырь китапларына күзем төшә. Марсельнең китапларына кереш сүзне күренекле якташыбыз, Г.Тукай премиясе иясе Фоат Садриев язган икән. Фоат абый фатиха биргәч, сыйфат билгесе инде бу! Соңрак сәхнә түреннән Марсельнең улы Рөстәм Гыйльфанов «Туган җиремә» җырын яңгыратып халыкны соклaндырды. Гомумән, туган җиребезгә мәхәббәт, гаилә темасы концертның башыннан ахырынача кызыл җеп булып сузылды. Шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗановның гаилә ансамбле, быел да төрле уен коралларында татар халык көйләренә тезмә башкарып, тамашачылар мәхәббәтен казанды. Гүзәл Минһаҗева, Сәләхетдин Гыймаев, «Сүнмәс дәрт» егетләр вокаль ансамбле... чыгышларын тыңлап никадәр рухи ләззәт аласың! Сөбханалла, талантлар күп Мөслим җирендә.

Былтыр «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсында республикабызның барча районнары да катнашса, быел, ни кызганыч, бөтенесе дә җөрьәт итмәгән. Билгеле, мәҗбүр итеп булмый. Казанга килүнең чыгымнары да аз түгелдер. Әмма мәдәниятка игътибарны киметергә ярамый, халык иҗаты казанышларын өлкән буыннан алып калырга, халыкка җиткерергә кирәк. Былтыр җиңүчеләрне өч төркемгә бүлеп, беренче, икенче, өченче урыннары биреп, бүләкләсәләр, быел катнашучыларны, районда яшәүчеләрнең санына карап, дүрт төркемгә бүлгәннәр. Шулай итеп, быел 12 призлы урын, бер гран-при биреләчәк.

– Былтыр гран-прига лаек булган Арча районы башкалардан нык аерылып торса, быел җиңүчене билгеләү шактый кыен булачак. Быел мөслимнәрнең әзерлеге бер башка югарырак. Ниндидер призлы урын алмый калмаслар дип уйлыйм. Шөкер, һәр районның үзенчәлеге бар. Әйтик, яңа өйләнешүчеләргә чигүле пар мендәр бүләк итү гадәте бер Мөслимдә генә сакланган. Рәхмәт мөслимнәргә: казаннарга зур бәйрәм ясадылар! – дип тәэсирләре белән уртаклашты жюри әгъзасы, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова.

**Рәшит МИНҺАҖ.**

# Бардада бар да бар

*Пермь краенда татар башкаласы дип йөртелгән Барда районы – милләттәшләребез күпләп яши торган төбәкләрнең берсе. Быел Барда округы оештырылуга 100 ел тулды. Шушы уңайдан Татарстанда өч көн дәвамында Барда районы мәдәнияте көннәре булып үтте. Аның кысаларында Казанның В.Ленин исемендәге мәдәни-ял итү комплексында районның 100 еллыгына багышланган «Сауммы, Казан – рухи башкала!» дигән зур концерт та булды.*




Бардалар концертка килүчеләрне күргәзмәләр белән каршы алды. Әлбәттә, иң әүвәл Пермь крае татарларының милли бренды булган Барда түбәтәенә күз төшә. Берсеннән-берсе матур итеп чигеп әзерләнгән милли баш киемнәре тегүче Альмира Миндиярованың кул эшләре икән. Ул инде 13 ел дәвамында түбәтәйләр, калфаклар, күлмәк бизәкләре чигеп якташларын киендерә. Машина белән дә, кул белән дә чигә. «Бик яратып алалар, чит илләргә дә алып китәләр», – диде ул. Рәссам-керамист Альмира Сармановaның үз куллары белән кызыл балчыктан ясаган чынаяклары, бокаллары, истәлекле ядкәрләре нәфислеге белән җәлеп итте. Альмира бу һөнәрне дүрт ел элек үз иткән, махсус миче булган остаханәсе дә бар икән.

Аңлашыла ки, күргәзмә Барда чәк-чәге һәм бәлешләре белән дә үзенә дәшеп тора иде.

Символик казлар биюе белән башланып киткән концерт Барда районы турындагы фильм белән дәвам итте. Аны караганнан соң, бардаларны Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән сәламләргә сәхнәгә күтәрелгән Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров «Бардада бар да бар икән», – дип куйды. Бу сүзләрдә хаклык бар. Барда округы үзенең 100 еллыгын яңа төзелгән һәм төзекләндерелгән спорт сарайлары, мәдәният йорты, сәнгать мәктәбе, төзекләндерелгән уку йортлары белән каршы алган. Быел җәй Бардада икенче тапкыр югары дәрәҗәдә,



70 мең кеше катнашында Бөтенроссия авыл Сабан туе узуын да, М.Җәлилгә һәйкәл ачылу тантанасын да хәтерлибез әле. Ә Г.Тукайга һәйкәл Барданың үзәк мәйданын күптәннән бизи инде. Данис Шакиров татар дөньясына Барда үстереп биргән мәшһүр шәхесләребезне дә искә алды. Күренекле композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, педагог Мәсгут Имашев, фольклорчы-галим, шагыйрь һәм милләтпәрвәр сәясәтче Рәшит Ягъфәров, композитор, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Луиза Батыр-Болгари, артистка, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Дамира Кузаева, танылган композитор Сәүбән Чуганаев, татар эстрадасы йолдызлары Гүзәл Уразова, Чулпан Йосыпова, Динара Фәхриева Барда округы авылларында туып үскән.

Данис Шакиров тамашачыларның игътибарын залда да, балконда да алма төшәрлек урын да калмавына юнәлтте. Дөрестән дә, тамаша залына өстәмә урындыклар, эскәмияләр кую да хәлне җиңеләйтмәде, диварга сөялеп басып концерт караучылар шактый булды.

«Пермь краендагы округны татар дөньясында өлге булырдай итеп алып бару – булдыклылар эше. Бу якларда тырыш милләттәшләребез яши. Барда безгә бик якын, бик кадерле. Алга таба да бергә һәм бердәм булып яшәргә язсын», – диде Д.Шакиров.

Барда муниципаль округы хакимияте башлыгы Хәлил Алапанов та һәр тармакта Татарстанның, бөтендөнья татар конгрессының ярдәмен тоеп яшәүләрен әйтте. «Советлар Союзы чорында саф татар авылларында барлык фәннәрне дә татар телендә укып үстек. Бүгенге шартларда да татар теле һәм әдәбияты дәресләрен читкә куйганыбыз юк. Бу мәсьәләдә Татарстан мәгариф министрлыгы бик нык ярдәм итә. Округта татарлыкны саклау авыр түгел. Губернаторыбыз да безгә бу мәсьәләдә һәрвакыт ярдәмгә килә», – диде район башлыгы.

Концертта Гүзәл Нуриханова җитәкчелегендәге «Җиңгәчәй» халык фольклор ансамбле, Татарстанның атказанган артистлары Чулпан Йосыпова, Айгөл Хәйри, Сәнифә Рангулова, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Динара Фәхриева башкаруындагы җырлар, Халыкара фестивальләр һәм конкурслар җиңүчесе Эльвина Туйгульдина, Алсу Имайкина һ.б. чыгышы алкышларга күмелде.

**Сөембикә КАШАПОВА.**
**Автор фотолары.**

**1 нче биттә** – Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай премиясе лауреаты Мөхәммәт Мәһдиев.

# Без белгән һәм белмәгән Дәрдемәнд



Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар шигърияте классигы, нашир, журналист, иганәче, җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең 165 еллыгына багышланган түгәрәк өстәл утырышы булып узды. Утырышны сәламләү сүзе белән институтның директоры Илгиз Халиков һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь, Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла ачып җибәрде. Сөйләшүдә татар әдәбият фәненең каймагы – мөхтәрәм галимнәребез Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Фәрит Яхин, Дания Заһидуллина, Әлфәт Закирҗанов, Г.Ибраһимов институтының Язма мирас үзәге җитәкчесе Илһам Гомәров, Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, язучылар Лирон Хәмидуллин, Казаныбыздагы Татар әдәбияты тарихы музее һәм Ш.Камал мемориаль фатиры җитәкчесе Айдар Шәйхин, тәрҗемәче Вера Хәмидуллина һ.б. катнашты. Уфа фән һәм технологияләр университетыннан күренекле галим Марат Шәрипов һәм олугъ шагыйрьнең оныгы Бату Рәмиев (Уфа) сөйләшүгә читтән торып кушылды.

Дәрдемәнднең ил гаме белән сугарылган шигырьләре, салдырган мәчет-мәдрәсәләре, нәшер иткән газета-журналлары, шулай ук язучыларыбызга каләм чарларга, бәһасез хезмәтләрен бастырырга мөмкинлек биргәне, аерым алганда, хөрмәтлебез Ризаэддин Фәхреддинне үз янына сыендырып, аңа алтмыштан артык хезмәт язарга шартлар тудырганы өчен олыласак та, мәшһүр шагыйрьнең тормышын вә иҗатын җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнмәвебез ачыкланды. Аерым алганда, әдәбият һәм тел галимнәреннән кала, мәсәлән, тарихчыларның бу шәхескә тиешенчә игътибар бирмәүләре ачык күренде. Бу җәһәттән Илһам Гомәровның чыгышы кызыксыну уятты. Галим Башкортстан җирлегендә урнашкан Юлык авылындагы Дәрдемәндкә кагылышлы ядкәрләргә аерым тукталды. Танылган шагыйребезнең Юлыкка өч яшендә килеп, башлангыч мәктәптә укыганы билгеле. Бу авылга 300 еллап элек Татарстаныбызның Казан арты татарлары нигез салган, дип бара галим. Һәм иске зиратта табылган Пүкәл авылыннан күренекле рухани Әднәм бине Әбүбәкер улы Габделлатыйфның кабер ташын дәлил итеп китерә. Юлык авылында шулай ук Дәрдемәнднең әтисе Мөхәммәтсадыйкка Оренбург осталары чалмалап эшләгән истәлек ташына да тап булганнар. Андагы язуларга караганда, Мөхәммәтсадыйк 1891 елда вафат булган. Ризаэддин Фәхреддин исә 1892дә үлде дип яза, хатыны Зыяфәт 1898дә вафат булды ди. Әмма ни өчен исеме Зыяфәт соң? Дәрдемәнднең әнисен Хәнифә дип белә идек, һәм тормышын өйрәнүче галимнәр барысы да Мөхәммәтсадыйкның бер генә хатын алуын, ягъни бүтән хатынга өйләнгәне турында рәсми документлар табылмавы турында яза. Мөхәммәтсадыйкныкы янында балаларының истәлек ташлары бар. Алар да аптыраштa калдыра. Ник дигәндә, Мөхәммәтсадыйк абзыйның биш баласы арасыннан өчесе кечкенә чакта вафат булган, Закир белән Шакирга гына бу фани дөньяда байтак яшәргә насыйп булган дип уйлый идек. Әмма истәлек ташларыннан күренгәнчә, бертуган меценат Рәмиевләрнең бер абыйлары Галихәйдәр – 24 яшендә, апалары Бибифатыйма дә шул яшьтә вафат булган. Тагын берсе – Гомәр, үлгәндәге яше күрсәтелмәсә дә, 1904 елда бакыйлыкка күчкән, димәк, ул да имчәк баласы булмаган дип уйларга нигез бар. И.Гомәров алтын приискаларның унбиш еллап Дәрдемәнднең әнисе Бибихәнифә исемендә булуы, аннары гына ире Мөхәммәтсадыйкка күчүе һәм ун еллап вакыт узгач уллары Закир һәм Шакирга тапшырылуы, нигездә идарә эше белән Шакир шөгыльләнүе турында да әйтте. Галим патша Россиясендә алтын чыгарган өчен ай буе эшләгәнгә 2 дән алып 7 сумга кадәр хезмәт хакы түләнгән, эше бик михнәтле булганга күрә, ял көнне чыгып эшләүчеләр, әгәр шул көнне алтын тапсалар, аны үзләренә калдыру хокукына ия булганы турында кызыклы мәгълүматлар да әзләп тапкан. Рәмиевләр приискаларында алтын запасы аз булганга күрә, уртача хезмәт хакы аена 3 сум була. Енисей буйларында исә – 7 сум, Себердә – 5 сум хезмәт хакы түләгәннәр, ди. Рәмиевләрдә төрле елларда 860 дан артык кеше эшләгәне, бертуган Закир һәм Шакирнең ил казнасына 6,5 мең тонна алтын биргәне турында мәгълүматлар да әһәмиятле. Шакир Рәмиевнең 1912 елда хаста хәлдә Мәскәүгә дәваланырга барганда, тимер юл станциясендә, поезд астында калуын да ишеттек. Өч баласының әтиләре күзалдында суга батып үлүе турында да мәгълүмат бар. Шул фаҗига Шакирны хаста иткәндер дә, бәлки... Юлык авылын барып күрә алмаучыларга тагын бер мәгълүмат кызык булыр – бүген анда Дәрдемәнд төзеткән берничә ядкәр бар. Алтын саклагыч таш амбарның асты гына калган. Атнасына алты көн эшләп, дүрт көн – ир-атларга, ике көн хатын-кызларга гыйлем тупларга мөмкинлек биргән, күренекле драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзинең әзләрен хәтерләп, аның «Галиәбану» әсәре куелуга шаһит булган һәм «Асылъяр» әсәре язылган китапханә дә кызганыч хәлдә. Дәрдемәнд салдырган ике катлы мәчет кенә ничек бар шулай сакланган. И.Гомәров Юлык авылындагы Дәрдемәнд исеме белән бәйле истәлекләргә Татарстаннан да, Башкорстаннан да бернинди игътибар булмавы җәһәтеннән борчылуын белдерде.

Сөйләшү барышында туган җире Оренбург губернасы Стәрлетамак өязе Җиргән авылында шагыйрь яшәгән һәм Орскида вафат булган йортларның кайда урнашуы турында да бәхәсләр булды. Юлыктан аермалы буларак, Җиргән авылында Дәрдемәнд истәлеген мәңгеләштерү өчен бераз эшләр башкарылган. Быел август аенда, мәсәлән, бюстын куйганнар. Орск шәһәрендә исә Дәрдемәндне яшь буын милләттәшләребез бөтенләй белмичә үсә, шушында үсмер чагы, яшьлеге үтсә дә, биредә өйләнүенә, беренче баласы дөньяга килүгә карамастан, бернинди истәлек тамга да юк. Шәһәрдә шагыйрьнең җеназасы үткән җомигъ мәчете сакланган. Шуның ишегалдында истәлеккә язулы стела кую тәкъдиме яңгырады. Ни аяныч, бөек Дәрдемәндебезнең каберенә барып дога кылу мөмкинлеге дә юк ич безнең. Билгеле булганча, 1921 елда ачлыктан (яки тиф авыруыннан) үлгәч, аны Җаек суының ташу саен ярлардан чыгып, Орск шәһәренең мөселман зиратын су басу сәбәпле, ерак түгел урнашкан Ильяс авылында җирләгәннәр. Бөек Ватан сугышы елларында исә биреге Тула шәһәреннән патрон заводын күчереп утыртканнар. Завод зурая барып, Ильяс авылын да, зиратны да «йоткан». Дәрдемәндебезнең кабере дә завод астында калган. Хәрби берләшмәгә үтеп керү тыелганга күрә, аны саклап калу, башка җиргә күчерү дә мөмкин булмаган. Орскида истәлеккә стела кую да, шәһәр башлыгыкларының әледән-әле алмашынып торуы сәбәпле, озакка сузылган һәм әлегә кадәр тормышка ашмаган...

Тагын бер мәсьәлә – Дәрдемәнднең хакимияткә мөнәсәбәте әледән-әле кызу бәхәсләр уята. Шагыйрьдән совет патриоты ясау дөресме, әллә ул да «кызыллар» хакимиятенең корбанымы? Дәрдемәнд бөтен алтыннарын совет властенә үзе теләп тапшырганмы, әллә мылтык терәгәч, исән калырга бүтән чара калмаганга, мөлкәтен биргәнме? Ярты Төркияне сатып алырлык акчасы булса да, ник шагыйрь мәхшәр эчендә калуны сайлаган? Бу сорауларга җавап биргәнче иң элек хәтеребездә Дәрдемәндкә кагылышлы шул еллардагы хәлләрне яңартыйк әле. Бер улы Морат «аклар» ягында сугышырга мәҗбүр була һәм тифтан үлә. Тагын бер улы Җәһфәр «кызыллар» ягында сугышканда кулсыз кала. Искәндәрнең хатыны тифтан үлә, аның нәни улы Бәшәрне Дәрдемәнд үзе тәрбияли. Гаиләсен шушы хәлдә калдырып, чит илгә китәргә шагыйрьнең ничек йөрәге житсен?!

*«... Ни газизрәк – бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкаддәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!..*
*Сөт калыр, ватан китәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!..»* –

дигән юлларны язган Дәрдемәнд авыр заманнарда милләтен калдырып китүне күз алдына да китермәгән, мөгаен.

Каләм тотып советлар җырын җырларга да керешмәгән ул.

*«... Куанды ил, канат какты мәләкләр,*
*Шашып, аң-таң булып шайтан*
*төкерде!..*
*Җитәр, җилкенмә, йолкынма,*
*көчел, син,*
*Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!*
*Җиһан тормыш туен иткән чагында*
*Синең урның – үлекләр аймагында...»* –

дигән юллар белән шагыйрь бу яңа хакимият тә милләтебезгә тәрәккыят итәргә, хөр яшәргә мөмкинлек бирмәячәге турында искәртмәгәнмени?!

Чаллыдан тәрҗемәче Вера Хәмидуллина чыгышы да уйланырга мәҗбүр итте. Ул Дәрдемәнд шигырьләренең бүгенге көндә иң зур нәшриятебездә аерым китап булып басылган русчага тәрҗемәләре бик түбән дәрәҗәдә дип белдерде, бүгенге көнгә кадәр шагыйрьнең бөек әсәрләренә тиң рәвештә башкарылган тәрҗемәләрнең юклыгына ачынды, киләчәктә китапларда бер генә авторга урын бирмичә, төрле шагыйрьләрнең иң шәп тәрҗемәләрен сайлап алып урнаштыру кирәклеген ассызыклады. В.Хәмидуллинаның әйтүенә караганда, XIX гасырда яшәгән шагыйрьне тәрҗемә итүче шул чор рус әдипләрен дә белергә тиеш. Дәрдемәндне русчага әйләндерүче автор исә Лев Модзалевский, Федор Тютчев шигырьләрен белми булып чыга. Ник дигәндә, Дәрдемәнд аларның аерым шигырьләрен татарчага әйләндергән, тәрҗемәче исә оригиналларын эзләп табасы урынга, кирәдән шуларны русчага әйләндереп (бу реверсив тәрҗемә дип атала) Модзалевскийны да, Тютчевны да, бөек Дәрдемәндне дә хур иткән. «Робагыйны – робагый, газәлне – газәл итеп, шигырьнең ритмын, үлчәмен саклап тәрҗемә итү мәслихәт», – дип йомгаклады сүзен Чаллы кунагы.

Сөйләшү барышында Казанда Дәрдемәнднең музеен булдыру кирәклеге турында әйтүчеләр шактый булса да, бу мәсьәлә тиз генә тормышка ашмаска охшап тора. Ник дигәндә, Татар әдәбияты тарихы музее һәм Ш.Камал мемориаль фатиры җитәкчесе Айдар Шәйхинның сүзләре белән әйтсәк, Казаныбызда аерым шәхесләргә багышланган музейлар күп булганга күрә, якын киләчәктә тагын берсен ачуларына ышаныч аз. Татар әдәбияты тарихы музее нибары 644 квадрат метр тәшкил итеп, аның 227 квадрат метры экспозиция максатында кулланылса да, 2024-2025 елда күргәзмәне үзгәртеп кору вакытында бер залны Дәрдемәндкә багышларга әзерләр. Әдәбият музееn үз канаты астына сыйдырган Милли музей шагыйрьгә кагылышлы әйберләрне сатып алырга да каршы түгел икән. Декабрьдә исә Дәрдемәнднең 165 еллыгына күргәзмә оештырырга ниятлиләр.

Аңлашылганча, сүз күбрәк нашир, хәйрияче, алтын приискалар хуҗасы Закир Рәмиев турында барды. Шигърияте исә ни дәрәҗәдә тикшерелгән соң? Филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина Тукаебызны өйрәнгән кебек, Дәрдемәндне дә һәр яктан комплекслы өйрәнү кирәклеген ассызыклады, моңа житди сәбәпләрнең берсе – аның татар дини шигърияттен дөньявига әйләндерә башлавы. «Дәрдемәнд беренче булып татар әдәбиятына милләт темасын тәкъдим итә. Һәм ул XX гасыр татар әдәбиятының төп темасына әйләнә. Дәрдемәнд шигърияттнең гомумкешелек фәлсәфәсенә йөз тотарлыгын беренче урынга куя. Символлар ярдәмендә эчтәлекне тирәнәйтү мөмкинлеген һәм татар шигъриятенең чиста, матур, музыкаль, нәфис, аһәңле булырга тиешлеген күрсәтә. Аннан соңгы татар шагыйрьләре Дәрдемәнд салган юлдан, ул башлаган фикерләрне үстереп китәләр», – дип нәтиҗә ясап әйтте галимә.

Сөйләшүдә Тукай энциклопедиясе үрнәгендә Дәрдемәнд турында фундаменталь басма һәм «ЖЗЛ» шәлкеменнән киң катлам укучылар өчен популяр телдә язылган китап булдыру мәсьәләсе күтәрелде. Милли китапханәгә Дәрдемәнд исемен бирү тәкъдиме яңгырады. Казаныбызда сынын бастырып кую кирәклеге әйтелде. Галимә Айгөл Ганиева меценатларны бүләкләү өчен Дәрдемәнд исемендәге алтын медаль булдыру тәкъдиме белән чыкты.

**Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА әзерләде.**

podpiska.pochta.ru

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КӨЧЕ –





*Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшчәнлек алып барган «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының «Халкыбызның көче – аның атаклы кешеләрендә, милләттәшләребездә» дип исемләнгән чираттагы күчмә утырышы Яшел Үзән районында узды. Әлбәттә, эшлекле җыенның шушы төбәктә үткәрелүе очраклы түгел иде. Яшел Үзән районының Шырдан авылында танылган татар мәгърифәтчесе, тел галиме, тарихчы, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы Каюм Насыйри туып үскән. Киләсе елда галимнең туууына 200 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Утырышта Россиянең – 10 төбәгеннән, республикабызның - 23 районыннан, Казакъстан һәм Кытайдан килгән аккалфаклар катнашты һәм Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Яшел Үзән район бүлекчәсе эшчәнлеге белән танышты.*

**Каюм Насыйри мирасы**

Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән танышу аның Казандагы музей-утарыннан башланып китте. Шәһәрнең Иске татар бистәсендә 2002 елда ачылган музей бинасы кайчандыр К.Насыйриның якын туганы Галиев мәчете мәэзине Мөхәммәтбәдигъ Хөсәеновныкы булган. Ул вакытта йорт өч өлештән торган, К.Насыйрига яшәү өчен шуннан бүлмә бирелгән. 1970 һәм 1990 елларда бу йорт янгынга дучар була, аннары ул элекке проектлар буенча кабат торгызыла. Хәзер бинаның беренче катында ул яшәгән бүлмәдә һәм икенче каттагысында Каюм Насыйрины галим, педагог буларак ача торган экспозиция аның тормышын һәм эшчәнлеген тулысынча күзалларга мөмкинлек бирә.

Аккалфакларны Каюм Насыйриның туган авылы Югары Шырданда Татарстанның атказанган төзүчесе, «Каюм Насыйри туган җирне яңартып торгызу» фондының башкарма директоры, «Акведук» проект оешмасының җитәкчесе Асия Гобәйдуллина каршы алды. «Шушы җирлеккә җан кертүче ханым», – дип таныштырды аның белән «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының рәисе Кадрия Идрисова. Бу дөрестән дә шулай. Асия Гобәйдуллина, Каюм Насыйри фондын булдырып, аны җитәкләп, киләчәге булмаган авыллар рәтенә кереп бара торган Шырданны үстереп җибәргән. Хәзер монда барысы да яңарып килә. Ул хәтта үзенең дә нигезен төзекләндереп корган.

Танылган галим Каюм Насыйри, Югары Шырданда туып-үсеп, ата-бабасыннан тормыш өчен кирәкле сыйфатларны сеңдереп, башлангыч белем, тәрбия алып, Казанга чыгып киткән, мәшһүр шәхесләребезнең берсе булып җитешкән. «Бөек якташыбызның туган авылын яңартып торгызып, бирегә кешеләр кайтып, тулы гаилә булып яшәсеннәр, дигән хыял белән эш алып барабыз», – диде Асия Гобәйдуллина.

Каюм Насыйри язмаларында фаразланганча, авылны алты гаилә килеп урнашып нигезләгән. Берсе – Каюм Насыйриның тамыры. Бу шәҗәрә өйрәнелгән. Иван Грозный Казанны яулагач, Шырдан якларында да үзгәрешләр башланган. Җирлектәге ике зиратның берсе Болгар чорына туры килүе дә авылның бик борынгы булуын күрсәтә. Кайнап торган авыл XX гасырның ахырында-XXI гасыр башында мескен хәлгә килә, халык якын-тирә шәһәрләргә барып урнаша, китми калганнары картая. Хәзер исә авылда кыш көне 65 кеше яши. Энтузиастлар өметләрен өзми, Шырданга яңа сулыш өрелсен дигән теләк белән аны яңартырга алыналар. Әлбәттә, эш бик җиңел бармый. «Бу вакыт узар, халык аңлар, кайтыр. Монда яшәү шартлары уңай, һавасы чиста. Авыл яшәр», – дип өметләнә алар.

Авылны торгызу эше 2015 елда башланып китә. Асия ханымның әти-әниләренең, туганнарының каберен зыярәт кылып кайтып килеше. Ул Бөек Ватан сугышы корбаннарына багышлап 1960 елларда куелган пирамида-һәйкәл янына туктала. Башына йолдыз куелган истәлек хәзерге заманга туры килми. «Мин – төзүче-инженер. Моны башкача эшләргә кирәк», – дип уйлана ул. А.Гобәйдуллина икенче көнне эшенә баргач, архитекторлар белән һәйкәл эскизын ясый һәм, авылга кайтып, җирлек җитәкчесе белән сөйләшә. 7 майга һәйкәлне торгызу турында килешәләр, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына бу эшне башкарып та чыгалар. Затлы да, заманча да монумент авылның бизәгенә әверелгән. Аңа Бөек Ватан сугышына киткән 300 кешенең исем-фамилиясе язылган. Алга таба инде Асия ханым авылны төзекләндерүнең концепциясен эшләп куя. Ул вакытларда Шырданда Каюм Насыйрины аның коесы һәм бюсты гына хәтерләтә торган була. Хәзер инде Асия Гобәйдуллина һәм аның командасы тырышлыгы белән авылда тулы бер архитектура комплексы үсеп чыккан. Кайчандыр Шырданда халык күп яшәгәч, икенче мәхәллә мәчетен салу мәсьәләсе дә килеп чыккан: Каюм Насыйри аны финанслауны үз өстенә алган – 1000 сум акчасын шушы мәчетне төзүгә биргән. Акча мәчет төзүгә тотылган. Әмма Аллаһы йортын файдалануга галимнең вафатыннан соң 1903 елда тапшырганнар. Ул мәчетне Асия ханымның бабасының әтисе Гыйбадулла абзый кабул итеп алган, бу хакта беркетмә дә саклана икән. Мәчетнең язмышы кызганыч: аның манарасын 1930 елларда кисеп-бәреп төшергәннәр, мәчетне исә башта мәктәп, соңрак контора иткәннәр. Хәзер исә мәчет, яңа фундамент салынып, Асия ханымның изгелеге белән өр-яңадан күтәртелгән. Иске мәчет бүрәнәләренең 80 проценты сакланган. Аларны ышкылап чистарткаsuccessнар. Моннан тыш Югары һәм Олы Шырдан арасындагы зират гадәти кыр-аланга әверелгән була. Узган ел Асия Гобәйдуллина тырышлыгы белән әлеге изге урын таш баганалар белән әйләндереп алынган һәм шунда таштан монумент урнаштырылган.

Каюм Насыйри исеме белән аталып йөртелә торган чишмә янында да булдык. Аның тирәсе дә ямьләндерелгән. Янында үсеп утыра торган тирәккә якынча 500 яшь икән. Ул Россиянең карт агачлар исемлеге реестрында тора. Шунда чишмәне бизәп торган картиналарга да игътибар иттек. Ел саен, балалар арасында галимнең туган көне уңаеннан, аның хезмәтләренә һәм туган җиренә багышлап, рәсем сәнгате конкурсы уздыру традиция булып әверелгән. Быел бәйгегә 220 эш килгән. Аларны Рушан Шәмсетдинов, Александр Филиппов кебек танылган рәссамнар бәяләгән, 49 эшне аерып алып, урыннар бирелгән. Җиңүчеләрнең эшләре К.Насыйри һәм Сабан туе чишмәләренә куелган. Әлбәттә, аларны алга таба җыеп алып урнаштырачаклар.

17 чишмәнең суын үзенә җыйган инеш тирәсе дә сазлыкка әйләнә башлаган була. Асия Гобәйдуллина командасы исә анда плотина төзергә алына, моның өчен башта грант оталар, аннан килгән финанслар чыгымнарның 46 процентын каплый, калганын үз көчләре белән башкарып чыгалар. Котлованны чистарталар, киңәйтәләр, яр буена бара торган мәйдан сукмагын урман хайваннары сыннары белән ямьләндерәләр. Хәзер инде Сабан туе уза торган мәйдан карап туйгысыз матур.

Авылга спорт мәйданчыгы да төзегәннәр. Анда мини футбол, баскетбол, волейбол, мини теннис уйнарга мөмкин. «Яшьләрнең игътибарын җәлеп итәргә кирәк», – ди А.Гобәйдуллина. Хәзер инде авылга кайтып өч көн булса да яшәп китәргә теләүчеләр күбәйгән. Асия ханым кунакханә төзергә дә ниятләүләре барлыгын искәртеп үтте.

А.Гобәйбуллина һәм аның командасы эшне алга таба да дәвам итә. Авылга, автобуслар белән керерлек юллар түшәү, тузган клубны сүтеп, яңасын салу буенча эшне Татарстан Рәисенә мөрәҗәгать итүдән башлап җибәргәннәр. «Каюм Насыйрига багышлап төбәкара конкурслар уздырганда, килүчеләрне кабул итәрлек клубыбызны булдыру турында хыялланабыз. Киләсе елда ике парк нигезләргә дә ниятлибез, берсе Бөек Җиңүнең – 80, икенчесе Каюм Насыйриның 200 еллыгына багышлана», – ди А.Гобәйдуллина. Энтузиастлар Геройлар аллеясы ясау турында да уйлана. Авылның махсус хәрби операциядә һәлак булган ике ир-егетенә багышлап стела да куярга да ниятлиләр.

Авылга бер килүебездә бүрәнәләре череп, иданнәре янтаеп беткән музей булуы хәтердә калган иде. Хәзер инде аны да яңартып эшләгәннәр. Ул халыкка Каюм Насыйри исемендәге китапханә-музей буларак хезмәт күрсәтә. Биредә 4600 китап һәм бай рухи мирасыбыз саклана. Аның белән безне мөдир вазифасын башкаручы Гүзәл Миңһаҗева таныштырды. Хәзер анда инде бакыйлыкка күчкән әдипләребезнең үзләре исән вакытта чыккан китапларын да, Гали Чокрый хаҗнамәсенең бер өлешен дә, «Йолдыз», «Дин вә мәгыйшәт», Кырымда нәшер ителгән «Тәрҗеман» газеталарының, «Шура» журналының кайбер нөсхәләрен дә күрергә мөмкин. Бик күп шәхесләребезгә белем биргән галимә Резе-

# АНЫҢ АТАКЛЫ КЕШЕЛӘРЕНДӘ



●Татарстанның атказанган төзүчесе, «Каюм Насыйри туган җирне яңартып торгызу» фондының башкарма директоры, «Акведук» проект оешмасының җитәкчесе Асия Гобәйдуллина.



да Ганиеваның да шәхси китапханәсендәге 1600 басма биредә урын алган.

Беренче календарьларны да Каюм Насыйри чыгарган һәм ул бу эшне 24 ел буе дәвам иткән. Алар халык арасында аеруча популярлык казанган. Галим, төрле темаларны өйрәнеп, 40 ка якын хезмәт язган. Кадрия Идрисова искәртеп үткәнчә, галим медицина өлкәсендә дә, туклану мәсьәләсендә дә, мәдәни мирасыбызны барлауда да гыйлемен өйрәтеп калдырган. К.Насыйри үзе исә «Минем иҗтиһатымның иң олысы «Мифтәх әл Коръән» дигән. Ул – Изге Китабыбызның әлифба тәртибендәге сүзлеге. «Казембек шушы хезмәтне 25 ел язган. Ул дөньяда зур танылу алган. Хәтта аны Иран солтаны 1нче дәрәҗә ордены белән бүләкләгән. Каюм Насыйри шушы хезмәтне 4 елда эшләп чыккан. Бернинди танылу алмаган. Казан университеты китапханәсендә шушы хезмәт 130 ел яткан», – дип сөйләде Гүзәл Миңһаҗева. Әлбәттә, галимнәр аны эзләгән. Каюм Насыйриның вафатыннан соң барлык мирасы университет китапханәсенә күчә. Хезмәтне галимнәр Айдар Хәйретдинов белән Рушания Шәфигуллина тапкан, күчермәсен алып халыкка җиткергәннәр. «Ул әле өйрәнелмәгән, Кирилл хәрефләренә дә күчерелмәгән. Каюм Насыйри «Мифтәх әл Коръән» хезмәте белән генә дә бөек дин галиме дип аталырга хаклы. Ул пәйгамбәрләр тарихын да язган. Әмма аны үзе үлгәнче танырга теләмәгәннәр. «Сукыр Каюм», «Урыс Каюм», «Агент Каюм» дип йөрткәннәр. Каюм Насыйриның дәвамчылары – Г. Исхакый, Г.Тукай, М.Гафури, З.Бигиев, Г.Чокрый», – дип сөйләде Гүзәл Миңһаҗева.

Вафатыннан соң «Тәрҗеман» газетасында галим турында кайгынамә басыла, анда беренче тапкыр Каюм Насыйри турында «Татарның бөек мәгърифәтчесе» дигән мәгълүмат бирелә. Аны Гаяз Исхакый шулай атый.

Шунысы аяныч, галимнең тууына 200 ел тулуны билгеләп үтәргә әзерләнәбез. Әмма бүгенге көндә дә Каюм Насыйри мирасы әле тиешенчә өйрәнелмәгән, алар китапханә киштәләрендә ята һәм галимнәребезнең игътибарын үзенә җәлеп итүне, өйрәнүне сорый.

### Гимназиядә милли яшьләр үсә

Соңгы вакытта телебезнең кулланылышы көннән-көн кими, мәктәпләребездә балаларның елдан-ел рус телендә аралашуга күчә баруы кемнәрне генә борчымый икән? Халкының 51 процентыннан артыгы – руслар, 43 проценты гына татарлар яшәгән Яшел Үзәндә бу хәлнең торышы ничек соң? «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы әгъзалары бу мәсьәлә белән дә кызыксынды.

Яшел Үзәннең «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе, Осиновоның С.Гыйматдинов исемендәге татар гимназиясе директоры Гөлинә Саттарова кунакларны үзе җитәкләгән уку йортында каршы алды.

Керә-керешкә үк гимназия бинасының яңалыгына, чисталыгына игътибар иттек. Быел укучылар белем алуларын зурдан кубып ремонтланган гимназиядә башлап җибәргән икән. «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова да уку йортындагы буяулар палитрасының шулкадәр дөрес һәм матур сайлануына соклануын белдерде. «Диварлары якты төсләргә буялган, аларны татар телендә язылган канатлы сүзләр бизәгән бу уку йортында белем алучыларга кызыгып та куйдык», – диде ул.

Гимназия бинасының төзелүенә ярты гасырга якын вакыт үткән булган инде. Ул башта рус мәктәбе буларак ачыла, 1994 елда татар гимназиясе итеп үзгәртелә. Хәзер ул – бу районда иң зур татар мәктәбе. Биредә барлык фәннәр туган телебездәге дәреслекләр белән татарча укытыла. Әмма беренче елларда укучыларны туплау шактый кыенга туры килә, ата-аналар балаларын татар мәктәбенә бирергә теләмәгән. Укытучылар Осиново бистәсендә, йорт саен кереп, татар балаларын гимназиягә укырга чакырып йөргәннәр. Хәзер исә уку йортында тиешеннән дә артыграк – 462 укучы белем ала. Гөлинә Саттарова бердәм коллектив туплый алган. Уку йортында тәртипнең әйбәт булуын, һәр балага индивидуаль якын килүләрен, тирән белем бирүләрен аңлап алган ата-аналар балаларын нәкъ менә шушы гимназиядә укытырга телиләр икән. Әмма уку йортының да мөмкинлекләре чиксез түгел.

«Мәктәптәге тәртипне, тәрбия мәсьәләләрен күреп, балабыз шушы мәктәптә укысын әле, дип сорап килүчеләр күп, урыныбыз гына җитми. Бездә мультилингваль укыту-тәрбияләү проекты эшли, укучыларыбыз татар рус, инглиз телләрендә иркен сөйләшә. Педагогларыбыз – көчле, укучыларыбыз – акыллы, әти-әниләребез дә ярдәмчел. Мин үзем дә, балаларым да татар мәктәбен тәмамладык. Алар БДИны югары балларга тапшырды. Татар телендә уку бердәм дәүләт имтиханын уңышлы тапшыруга берничек тә комачауламый», – диде Гөлинә Саттарова. Аның бу сүзләрен чыгарылыш сыйныфы укучыларының уңышлары да раслый. Соңгы өч елда ике укучы химиядән БДИны 100әр баллга тапшырган. Гимназияне тәмамлаучылар шулай ук математика, рус теле, физика, җәмгыять белеменнән дә 98 баллга кадәрле нәтиҗәләргә ирешәләр, уку йортын алтын медальгә тәмамлаучылар да хәтсез икән.

Директор кунакларның игътибарын диварларга эленгән стендларга юнәлтте. Анда исә – гимназия шәҗәрәсе, уку йортының тарихы, җитәкчеләренең, 1994 елдан алып бүгенге көнгә кадәр IX-XI сыйныфларда укучыларның фотосурәтләре. «250 әти-әнинең 100дән артыгы шәҗәрәсен ясап китерде. Бишәр бала үстерүчеләр дә бар. Шәҗәрә төзүгә җәлеп итүне беренче класста укучылардан ук башлыйбыз. Әти-әнисен, әби-бабасын белеп, язып китерсә, риза булабыз. Эш шуннан башлана, алга таба тирәнәеп дәвам итә», – дип сөйләде Гөлинә Саттарова. Гимназиядә кайсы да булса укучының кырын эше сизелсә, аның белән теләсә кайсы укытучы сөйләшә. Аннары мәсьәләне бергәләп хәл итәбез. Мин моны практик буларак әйтәм», – диде ул.

Гимназиядә берничә музей булуы да укучыларда үткәннәребезгә, үз эшен намус белән башкарып, халыкта ихтирам яулаучыларга хөрмәт тәрбияли. Уку йорты танылган партия эшлеклесе, РСФСР авыл хуҗалыгы атказанган хезмәткәре Саяс Кыям улы Гыйматдинов исемен йөртә, биредә аның музее да булдырылган. Укучылар исә Саяс Кыям улының алга куелган мәьәләләрне уңышлы хәл итүгә коллективны бер йодрыктай туплап эшли белүче, энергияле, талантлы оештыручы, шул ук вакытта һәр кешенең хәленә кереп ярдәм кулы да сузучы, киңәшләре белән ярдәм итүче талантлы җитәкче булуы турында өч телдә сөйли. Хәзер Осиново гимназиясендә «С.К.Гыйматдинов укулары» төбәкара фәнни-гамәли конференциясен уздыру күркәм традициягә әверелгән. Ул узган ел алтынчы тапкыр үткәрелгән.






(Дәвамы 19 нчы биттә).

# Фәрһад белән Ширин кебек...

## яки *Үтәлгән нәзер*





● София Гобәйдуллина.

*Ташкент өлкәсе Бекабад шәһәрендә гомер кичергән алар. Памир һәм Тянь-Шань таулары арасында урнашканга күрә, бик яраткандыр бу шәһәрне Мәгъдүмә апа. Мәһабәт кыялар аңа Ютазы районы Ташкичү авылы янындагы тауларны хәтерләткән булса кирәк. Биек таулар, куе урманнар, сыргаланып аккан елгалар турында ничәмә тапкырлар балаларына сөйли ул. Камил әнисенең хикәятләренә гашыйк булып үсә. Сәнгать мәктәбенә укырга кергәч, ул әнисенә Ютазыга кайтып, әкияти матур авылны сурәткә алырга сүз бирә. Ни аяныч, Мәгъдүмә апа бу сурәтләрне күрергә өлгерми.*





Яшь кыз чагында Үзбәкстанга килеп урнаша Мәгъдүмә апа. Шунда Башкортстанның Чишмә районы Илкәш авылыннан Нәбиәхмәтне очрата. Егет Бөек Ватан сугышында яраланып кайткан, шофер булып эшли. Матур гына яшәп китәләр. Ел артыннан ел узганы сизелми дә. Уллары Камилгә дә башлы-күзле булырга вакыт җитә. Бекабад шәһәре Фәрһәд кыясы янында урнашкан. Шуннан ерак түгел Сырдарья елгасының арьягында исә – Ширин тавы. Шуңа күрә биредә Фәрһад һәм Ширин турында матур риваять аеруча таралган. Ибраһимовлар гаиләсендә дә бу әкиятне Ташкичү авылының гүзәл табигате турындагы хикәятләрне кебек үк бик еш ишетәләр. Бер көнне Камил Ибраһимов Ширин тавы буендагы авылдан Василә исемле кызга гашыйк булып куймасынмы! Әйтерсең, алар мәхәббәтне Фәрһад белән Шириннән әманәт итеп ала. Гомер итә башлауларына 46 ел. Мәхәббәтләре исә һаман яңа, һаман саф.

2005 елда Ибраһимовлар гаиләсе Мәгъдүмә апаның туган ягы Ютазыга кайтып Кече Урыссу авылында төпләнә. Бүген Камил Ибраһимов районда гына түгел, Татарстаныбызда күренекле рәссам, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе. Барыннан да яратыбрак нәрсә ясый дисезме? Әлбәттә, авылны яратып сурәткә иңдерә. Тәрәзә төпләрендәге яран гөлләрне, бизәкле агач капкаларны, челтәрле тәрәзә читлекләрен, сизелер-сизелмәс кенә үләннәрне иркәләп искән таң җилләрен, иртәләрен елга өстендә җәелгән сихри ак томаннарны, тулышкан алтын игеннәрне, су буендагы елак өянкеләрне әле болай, әле тегеләй сурәтли. Әнисенең сөйләгәннәре хәтеренә шулкадәр әйбәт уелган, хәзер ул күңелгә газиз авылны күзен йомып та киндергә иңдерә алыр иде кебек. Татар авылына үзе генә гашыйк булып калмады, күпләгән рәссамнарны да бирегә җәлеп итте. Күренекле рәссамыбыз Мөдәррис Минһаҗев республикабыз районнары буенча пленерлар башлап җибәргәнен беләбез. Камил Ибраһимов белән бергә алар Ютазыда да менә инде дүрт пленер үткәргәннәр. Татарстаннан гына түгел, Россиянең төрле шәһәрләреннән дә Ютазыга рәссамнар килгән һәм Мәгъдүмә апа гомере буе кадерле ядкәр итеп саклаган гүзәл табигатьне үз күзләре белән күреп, гашыйк булып киткән. Рәхмәт йөзеннән илһам биргән төбәккә картиналарын да бүләк итеп калдырганнар. Камил ага инде өченче ел Башкортстандагы «Бабай утары» белән хезмәттәшлек итә. Аны эшмәкәр, химаяче, шагыйрь, композитор, музыкант Фәнир Галимов булдырган. «Бабай утары»н ачык һавадагы музей диләр. Биредә иҗатчыларның төрледән-төрле фестиваль-бәйгеләре, бәйрәмнәре уза икән. Камил Ибраһимов исә бу урынга рәссам халкын да җәлеп итәргә ярдәм иткән, гүя этисе Нәбиәхмәтнең туган җиренә дә матур сәнгатьнең барып ирешүен теләгән.

Ибраһимовлар гаиләсе белән Казаныбызда ютазыларның иҗат бәйрәмендә таныштык. Анда исә Камил аганыкын гына түгел, кызы Альбина һәм оныгы Алинәнең дә рәсемнәрен күрдек. Фәрһад белән Ширин кебек мәхәббәтле, әби-баба, ата-ана сүзен хөрмәт итеп яшәүче матур татар гаиләсенә сокланып кайттык.

**Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.**





podpiska.pochta.ru

Мәдәни җомга

РЕСПУБЛИКА МАТБУГАТ һӘМ МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯЛӘР АГЕНТЛЫГЫ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН ЧЫГАРЫЛА

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

БАШ МӨХӘРРИР ВАЗИФАСЫН БАШКАРУЧЫ

**Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)**

**Шылтыратыгыз:**

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

**Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)**

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

**Индекс П2355**

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

©Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

**Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:**

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

**НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ**

420097, Казан, Академия урамы, 2

**Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

**«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru**

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

**Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 29.11.2024**

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2450 данә

Заказ 2757

16+